# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылы торак пунктында 2025 елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 14 ноябре** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Сарысаз-Тәкермән авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарысаз-Тәкермән авылы Иске Имән авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); Сарысаз-Тәкермән торак пунктында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдирование);

2) электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен,трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Сарысаз-Тәкермән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыю (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Иске Имән авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында

(https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Ә.Исламова